Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге Советы

**КАРАР** № IX-1

Олы Әшнәк авылы 2024 елның 11 нче октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 маендагы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләр, вазыйфаи айлык хезмәт хакы, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү системасы үзгәрүгә бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәрләрнең, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга социаль гарантияләрне тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсе, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 маддәсе, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында” 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары, “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә күпьеллык хезмәт өчен пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган кызыксындыруны түләү тәртибе турында” Нигезләмәне раслау хакында 2005 елның 29 декабрендәге 666 номерлы карары, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгу сәбәпле Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 10 июлендәге 353 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз

вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Олы Әшнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 маендагы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләр, вазыйфаи айлык хезмәт хакы, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» 7 номерлы карарына (29.09.2020ел, №II-1 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары» 1 нче кушымтасын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

1.2) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи айлык хезмәт хаклары күләмнәре» 2 нче кушымтасын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

1.3) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә айлык акчалата кызыксындыру күләмнәре һәм аны гамәлгә ашыру тәртибе» 6 нчы кушымтасын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

1.4) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә классы чин өчен айлык өстәмә түләү күләмнәре һәм тәртибе» 7 нче кушымтасын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

1.5) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фондын булдыру тәртибе» 12 нче кушымтасын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорт; Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Балык Бистәсе муниципаль
районы Олы Әшнәк
авыл җирлеге Башлыгы: Р.Ә. Хөснетдинова

–

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Олы Әшнәк авыл җирлеге
Советының 2018 елның 07 маендагы
_____7 номерлы карарына
кушымта №1,
Олы Әшнәк авыл җирлеге
Советының 2024 нче елның 11
октябрендәге IX-1 номерлы карары
редакциясендә

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында
муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга
хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары

| Вазыйфаның аталышы | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 12 төркем |
| Авыл җирлеге башлыгы | 18 260 |

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларына, депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен билгеләү максатларында тиешле муниципаль берәмлекнең статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына бәйле рәвештә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен хезмәт өчен түләү төркемнәренә кертү күрсәткечләре кертелә.
Күрсәтелгән күрсәткечләргә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "______ авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уникенче төркемгә кертелде - халык саны 1,5 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлек буларак.
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затка «Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә (алга таба - муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче зат), Татарстан Республикасы норматив актларында айлык акчалата бүләкләүдән тыш башкасы каралмаган очракта, өстәмә рәвештә билгеләнә:

1) матди ярдәм;
2) ай саен акчалата кызыксындыру;
3) эш нәтиҗәләре буенча премия;

4) еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләү;

5) федераль законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр.

Авыл җирлеге башлыгына ай саен акчалата бүләкләү түләнә. Авыл җирлеге башлыгы хезмәтенә түләү чыгымнары күләме ай саен акчалата кызыксындыруны түләү өлешендә авыл җирлеге башлыгы өчен елга 12,86 айлык акчалата бүләкләү нормативыннан артмаска тиеш.

Еллык түләүле отпуск биргәндә авыл җирлеге башлыгына бер мәртәбә түләнә торган түләү айлык акчалата түләүдән артмаган күләмдә түләнә.

Сайланулы вазыйфаи затның һәм (яисә) аның якын туганнарының каты авыруы, үлеме һәм башка бәхетсезлек очраклары булганда авыл җирлеге башлыгына матди ярдәм түләнергә мөмкин. Премиянең конкрет күләме матди ярдәм түләү турында муниципаль хокукый актта күрсәтелә. Матди ярдәм түләү хезмәткә түләү фондын экономияләү исәбенә башкарыла, матди ярдәм түләү өчен нигез булып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Әшнәк авыл җирлеге Советы карары белән рәсмиләштерелгән муниципаль хокукый акт тора. Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә авыл җирлеге башлыгы айлык акчалата бүләкләүгә түбәндәгеләрдән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Муниципаль хезмәт стажы | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 тән 10 га | 10 |
| 10 нан 15 кә | 15 |
| 15 елдан артык | 20 |

Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү чыгымнары күләме авыл җирлеге башлыгы вазыйфасы буенча елына өч айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итә торган нормативтан артмаска тиеш.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы  Олы Әшнәк авыл җирлеге
Советының 2018 елның  07 маендагы
7 нче номерлы  карарына
кушымта №2,
Олы Әшнәк  авыл җирлеге
Советының 2024 нче елның 11
октябрендәге IX-1 номерлы карары
редакциясендә

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең
вазыйфаи айлык хезмәт хаклары күләмнәре

1. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи айлык хезмәт хаклары күләмнәрен билгеләү өчен тиешле муниципаль берәмлекнең статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына бәйле рәвештә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен хезмәткә түләү төркемнәренә кертү күрсәткечләре кертелә.
Күрсәтелгән күрсәткечләргә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "_____ авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уникенче төркемгә кертелде - халык саны 1,5 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлек буларак.

1. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәтенең биләгән муниципаль вазыйфасына бәйле рәвештә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладына кабатлы күләмдә билгеләнә, ул 13 323,0 сум тәшкил итә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Әшнәк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның аталышы | Коэффициент |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 1,37 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (сәркатип) | 1,33 |
| Әйдәүче белгеч | 1,11 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 1,00 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы  Олы Әшнәк авыл җирлеге
Советының 2018 елның  07 маендагы
7 нче номерлы  карарына
кушымта №6,
Олы Әшнәк  авыл җирлеге
Советының 2024 нче елның 11
октябрендәге IX-1 номерлы карары
редакциясендә

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
______ авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә
айлык акчалата кызыксындыру күләмнәре һәм аны гамәлгә ашыру тәртибе

Айлык акчалата кызыксындыру вазыйфаи окладның 41 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә,  җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертүгә бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда муниципаль хезмәткәрне элек биләгән вазыйфаи окладына караганда азрак булган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләү очрагыннан тыш,  бу очракта акчалата кызыксындыру күләме муниципаль хезмәткәрнең акчалата түләвен ул элек биләгән вазыйфа буенча акчалата түләү күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып исәпләнә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы  Олы Әшнәк авыл җирлеге
Советының 2018 елның  07 маендагы
7 нче номерлы  карарына
кушымта №7,
Олы Әшнәк  авыл җирлеге
Советының 2024 нче елның 11
октябрендәге IX-1 номерлы карары
редакциясендә

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә класслы чин өчен айлык өстәмә түләү күләмнәре һәм тәртибе

1. Класслы чин өчен айлык өстәмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәре тарафыннан бирелгән класслы чин  нигезендә түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Класслы чинның аталышы | Өстәмә күләме (вазыйфаи окладтан процентларда) |
|---|---|
| I класслы  хакыйкый муниципаль киңәшче | 7 |
| II класслы  хакыйкый муниципаль киңәшче | 5 |
| III класслы  хакыйкый муниципаль киңәшче | 3 |
| I класслы  муниципаль киңәшче | 7 |
| II класслы  муниципаль киңәшче | 5 |
| III класслы  муниципаль киңәшче | 3 |
| I класслы  муниципаль хезмәт киңәшчесе | 7 |
| II класслы  муниципаль хезмәт киңәшчесе | 5 |
| III класслы  муниципаль хезмәт киңәшчесе | 3 |
| I класслы  муниципаль референты | 7 |
| II класслы  муниципаль референты | 5 |
| III класслы  муниципаль референты | 3 |
| I класслы  муниципаль хезмәт сәркатибе | 7 |
| II класслы  муниципаль хезмәт сәркатибе | 5 |
| III класслы  муниципаль хезмәт сәркатибе | 3 |

2. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин өчен айлык өстәмә муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә класслы чин бирелгән көннән түләнә.

3. Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфаларының элек биләгәненә караганда югарырак төркеменә керә торган муниципаль хезмәт

вазыйфасына билгеләнгән очракта, ул биләгән вазыйфа керә торган вазыйфалар төркеме өчен беренче класслы чин бирелгәнче аның класслы чин өчен оклады күләмен исәпләү вазыйфаи окладка карата 3 процентка тигез процент ставкасыннан чыгып башкарыла.

4. Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфаларының элек биләгәненә караганда түбәнрәк төркеменә керә торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнеп куелган һәм элек биләгән вазыйфасы буенча аңа класслы чин бирелгән очракта, класслы чин өчен оклад күләме вазыйфаи окладка карата 7 процентка тигез процент ставкасыннан чыгып исәпләнә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Олы Әшнәк авыл җирлеге
Советының 2018 елның 07 маендагы
7 нче номерлы карарына
кушымта №12,
Олы Әшнәк авыл җирлеге
Советының 2024 нче елның 11
октябрендәге IX-1 номерлы карары
редакциясендә

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә
хезмәт өчен түләү фондын булдыру тәртибе

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда вазыйфаи окладларны түләү өчен җибәрелә торган акчаларның суммасыннан тыш түләү өчен акчалар карала (бер елга исәпләгәндә 12 вазыйфаи окладтан чыгып):

1) класслы чин өчен айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның дүрт процентыннан артмаган күләмдә;

2) муниципаль хезмәттә тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның унөч процентыннан артмаган күләмдә;

3) муниципаль хезмәтнең махсус шартлары (катлаулылыгы, киеренкелеге, хезмәттәге югары казанышлары, махсус эш режимы) өчен айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның биш процентыннан артмаган күләмдә;

4) аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр - вазыйфаи окладларның бер процентыннан артмаган күләмдә;

5) еллык түләүле отпуск биргәндә - вазыйфаи окладларның ун процентыннан артмаган күләмдә бер мәртәбә түләү;

6) айлык акчалата кызыксындыру - вазыйфаи окладларның 41 процентыннан артмаган күләмдә.